Казан шәһәре Совет районы “күп профильле
181 нче мәктәп”
№8 апрель 2019 ел

# «Күкнең җиденче катында»

**БУ САНДА:**

*Мәктәп яңалыклары.*
*Безнең уңышлар*
*Бирегез мәйдан!*

*Газетабызның апрель саны*
*Төкле аягың белән!*

## Мәктәп яңалыклары...

### Конференция

3 нче апрельдә укучылар һәм укытучыларның Е.А. Боратынский исемендәге “Яратырга өйрәнегез!” конференциясе узды.
5 нче “Б” сыйныфы укучысы Асланова Нәргиз (укытусы:Галиева А.Р.) һәм 8 нче “Б” сыйныфы укучысы Солдатова Алена (укытучысы: Володина Т.С.) призер булдылар.

### Музейга сәяхәт

23 апрель көнне 6 “Г” сыйныфы укучылары, сыйныф җитәкчесе белән, Казан вертолет заводында булдылар. Экскурсия музейдан башланды, анда балалалар завод тарихы белән таныштылар, самолетның беренче моделен һәм монда җитештерелгән вертолетлар күрделәр. Соңгы эшкәртү цехында балалар вертолет җыюның төрле стадияләре белән таныштылар. Шулай ук МИ-8 хәрби вертолеты пилот кабинасында булдылар.

### 7 нче апрель- Бөтендөнья сәламәтлек көне

7 нче апрель- Бөтендөнья сәламәтлек көне. Сәламәтлек – ул кешегә табигать биргән иң зур байлык. Бу көн сәламәтлекнең кеше тормышындагы ролен һәм аны ничек сакларга икәнен аңлату өчен билгеләп үтелә.

Сәламәтлек көне 1950 нче елдан башлап ел саен уздырыла башлый. Ул кешеләр сәламәтлекнең нинди зур әһәмияткә ия икәнлеген аңласын һәм халыкның сәламәтлеге бөтен дөньяга тагын да яхшырсын өчен нәрсә кирәклеген хәл итсен өчен үткәрелә.

Безнең мәктәбебездә дә бу Сәламәтлек көне үткәрү традициягә кереп бара.
5 апрельдә барлык балалар тәнәфесләрдә сәламәт яшәү турында фильмнар карадылар.Фильмнан соң балалар дөрес туклану әһәмиятенең нәтиҗәсен күреп, аңлап дәресләренә киттеләр.

### Гуманитар фәннәр атналыгы

Гуманитар фәннәр атналыгы кысаларында бишенче сыйныф укучылары “Без-грамоталылар!” интеллектуаль – күңел ачу уенында катнаштылар.
Командалар берничә сынауны уңышлы узды, аларда белем генә түгел, стандарт булмаган фикерләү, рисклы карарлар кабул итү кирәк иде.
5Д сыйныфының капитаны Грабалова Оксана һәм аның җитди һәм тәвәккәл командасы җиңде.

22 нче апрель көнне 2-4 нче сыйныф укучылары арасында инглиз телендә шигырь укучылар бәйгесе узды. Жюри хөкеменә төрле шигырьләр тәкъдим ителде:классик һәм заманча, күңелле һәм шаян, дулкынландыргыч һәм романтик шигырьләр. Кайбер шигырьләр чын мини- спектакльләргә әверелде.

12 нче апрель- Космонавтика көне

12 нче апрель Космонавтика көнен билгеләп үтәбез.
1961 нче елның 12 апрелендә, дөньяда беренче буларак, бортына кеше утырган "Восток" космик корабле җир тирәли орбитага чыгарылды. Бу кеше - очучы космонавт Юрий Алексеевич Гагарин. Гагаринның корабле, планетабыз тирәли орбита буенча 108 минутта тулы әйләнеш ясап, уңышлы рәвештә җиргә төште. 2019 елның 12 апрелендә Гагаринның беренче тапкыр космоска очуына 58 ел тулды.
Мәктәбебездә шул уңайдан күп кенә чаралар үтте. Укучылар беренче очучы – космонавт Юрий Гагаринның тормыш юлы һәм эшчәнлеге белән таныштылар, аның турында видеофильм карадылар, башваткычлар чиштеләр, космонавтика белән бәйле кул эшләре ясадылар.

24 апрель – директор чыгышы.

24 нче апрель көнне мәктәбебез директоры Абдуллина Д.А. , Совет районы башлыгы Р.Р.Фәхретдинов, Казан шәһәренең Совет районы мәгариф идарәсе башлыгы Э.Р.Арсланова һәм ата-аналар каршында "Казан шәһәре Совет районының 181 нче күп профильле мәктәп эшчәнлеге нәтиҗәләре" темасына чыгыш ясады.
Чыгышында 2018-2019 нчы уку елында мәктәп эшчәнлеге белән таныштырды.
Мәктәбебез ничек яши, алга таба нинди планнар һ.б. күп кенә мәсьәләләр яктыртылды.
Чыгышны бик игътибар белән кызыксынып тыңладылар.

26 апрель – Туган тел көне.

26 нчы апрель көнне бар татар дөньясы Туган тел көнен бәйрәм итә. Әлеге бәйрәм халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайның туган көне уңаеннан 1992 елның 22 февраленнән игълан ителгән.
Туган телем! Синең матурлыгың, синең газизлегең, синең кирәклегең турында кемнәр генә нинди матур сүзләр әйтмәгән! Сөекле Тукаебызның "Туган тел"е татарларның гимнына әверелде. Җиде миллионлы татар җырлый аны. Тел турында дистәләгән, йөзләгән мәкаль бар. Әле алар да аның бөтен сыйфатларын аңлатып җиткерә микән?
Тел-күңелнең көзгесе, ачкычы.
Баланың беренче көннәреннән үк туплый башлаган хәзинәсе – туган тел. Ана теле-тою, сизү, йөрәк теле, рухи тамыр. Туган телебез татар теле- борынгы һәм һәрьяклап үсеш алган төрки телләрнең берсе.
Туган тел бәйрәмен мәктәбебездә дә билгеләп үттек. 24 нче апрель көнне шигырь укучылар бәйгесе узды. Укучыларыбыз Тукай шигырьләрен сөйләделәр, кичә "Туган тел" җыры белән тәгәлләнде.
26 нчы апрель көнне Тукай әкиятләре сәхнәләштереп күрсәтелде. Укучылар, килгән кунаклар бик канәгать калдылар.
Тукай фани дөньяда кыска гына гомер кичерсә дә, халкыбызның сөекле һәм кадерле улы буларак дан һәм хөрмәткә күмелеп тарихта калды. Киләчәк буын да аны шулай зурлап йөрәк түрләрендә мәңге саклар, дип ышанасы килә.

**Шүрәле**

И, Шүрәле, Шүрәле,
Карап тора, күр әле!
Аның белән уйнамаска,
Йөрәкләрең түзәме?!

Аяк, куллары бик озын,
Кәкре борыннары.
Алар урманны ярата,
Урманда урыннары.

Ул кытыклый кешеләрне,
Ул кытыклап көлдерә.
Аягы озын булганга,
Ул бик каты йөгерә.

Урманнарга барсак та без,
Шүрәлегә тимиек.
Аның матур күлмәкләрен,
Өстебезгә кимиек.

**Су анасы**
Бу дөньяда һәр адәмнең
Яши ата-анасы.
Тирән суларда яшидер,
Суның да бит анасы.

Су анасы бик куркыныч,
Карап торсаң куркыта.
Әгәр ачуын китерсәң,
Сине дә куып җитә.

# Котлыйбыз!

## “Озын тәнәфес”шәһәр фестивале

16нчы апрельдә “Озын тәнәфес” бәйгесе дә тәмамланды.
Мәктәбебез 3 нче урынга лаек булды һәм 300 мең сумлык сертифатка ия булды. Бу акчалар мәктәпкә махсус җиһазлар алу өчен тотылачак.
Бәйгенең йомгаклау өлеше зур Гала концерт белән тәгәлләнде. Анда сайлап алу турларын узган иң яхшы чыгышларны тәкъдим иттеләр. Казан шәһәре мэры Илсур Метшин әйтүенчә, “Озын тәнәфес”-ул укучылар, аларны әзерләгән әти-әниләре, педагоглары өчен дә күңелле вакыйга. “Теләсә кайсы җитәкче дә үз мәктәбен, укучыларын мактау пьедесталында күрергә тели. Ләкин бу- бәйге, әмма, анда җиңелүчеләр юк. Нәтиҗә бер: балалар безне ел саен талантлары белән сөендерә, иҗат җиңә”,- диде Илсур Метшин.
Фестивальдә 3 нче урынны яулавыбыз Worldskills чемпионатына да әзерлек тә, чөнки мәктәп чемпионат кунакларын каршы алачак.

## “Ягымлы яз” фестивале

Ягымлы яз (фестиваль) («Ягымлы яз» ачык Казан милли иҗат фестивале) — Казанда яз айларында уза торган татар яшьләренең милли иҗаты ачык фестивале. 1993 елдан башлап үкәрелә.
Милли сәнгатькә йөз тотып, 1992 елдан бирле ел саен уздырыла торган фестиваль быел театр елына багышланды. Чара программасы үз эченә хореография, вокал, театр, мода театры, шигырь язучы авторлар конкурсы юнәлешләрен алды. Шулай ук, фестиваль кысаларында “Ягымлы Язбикә” дә сайланды. Жюри рәисе — Татарстанның халык артисты Римма Ибраһимова булды.
Бу фестивальдә безнең укучыларыбыз да катнаштылар, “Классик театр” номинациясендә, 9нчы сыйныф укучылары , Вилданова Алинә һәм Хәйруллин Булат 3 нче урынга лаек булдылар.
Җиңүчеләребезне чын күңелдән котлыйбыз һәм алга таба иҗади уңышлар телибез!

## Математик турнир

12 нче апрельдән 14нче апрельгә кадәр шәһәребездә Н.Г.Чеботарев исемендәге халыкара математик турнир булды.
4 нче А сыйныфы укучылары Сафин Мөхәммәт, Камалова Самира, Морозов Никита, Ханнанова Алсу (укытучы: Зарипова И.В.)
3 көн дәвамында Россиянең төрле шәһәрләреннән килгән командалар белән көч сынаштылар. Турнир нәтиҗәләре буенча безнең 4 А сыйныфы командасы III призлы урынга лаек булды.

## Бөек Җиңүнен 74 еллыгына

4 нче апрель көнне безнең гимнастларыбыз “Бөек Җиңү наследниклары “ дигән шәһәр конкурс-фестивалендә (180 нче гимназия) катнаштылар.
Фестиваль Җиңүнең 74 еллыгына багышланган иде.
Кунаклар:Бөек Ватан сугышчылары, тыл ветераннары иде. Килгән кунаклар бик канәгать калдылар.

## Макулатура тапшыр-агачны коткар!



Мәктәбебездә, 24 нче апрель көнне, сыйныфлар арасында макулатура җыю буенча ярышлар узды. Бу идеяне укучылар һәм аларның ата- аналары белән берлектә укытучылар да шундук хуплап алды.
Һәркемнең өендә актуальлеген югалткан китаплар, иске кәгазь каталоглар, күптән укылган матбугат басмалары хәйран булып чыкты. Нәтиҗәдә бик күп күләмдә кәгазь чималы җыеп алынды 1А сыйныф, 2Е сыйныф, 4Б сыйныф, 2В сыйныф укучылары ЭКО марафонның лидерларына әверелде.

## 1 апрель –Көлке көне

Көлке бәйрәме кайчан барлыкка килгән соң? Бу традиция борынгы заманнарда язны каршылау бәйрәме булып саналган. Бу көнне кешеләр кышның усал өрәген сурәтләүче карачкыны җирләгәннәр. Аның үлеменә кем гаепле икәнен белмәсен өчен анда катнашучыларның барсы да маска кигәннәр.

Шуннан бирле 1 апрельдә алдау гадәте кергән. Бу көн юмор, көлү, күңел ачу көненә әйләнгән. Россиядә бу бәйрәмнең кайчан һәм кем тарафыннан кертелүе мәгълүм түгел. 1 апрель шаяртулары Россиядә Петр 1 заманыннан бирле билгеле.Бу көнне Россиядә генә түгел, башка илләрдә дә билгеләп узалар.Күп илләрдә 1 апрельдә көлү, шаяру, дусларча алдашу көнен билгеләп узалар. Аның барлыкка килүен беркем дә төгәл генә әйтә алмый. Кайберәүләр аның тарихы Борынгы Рим чорына ук барып тоташа, ди. Тәңречелек заманында Көлке алласы хөрмәтенә Наданнар бәйрәме уздырганнар. Һиндстанда исә йола буларак такмаклар бәйрәмендә күңел ачканнар. Элек 1 апрельдә кояшның язгы торгынлыгы бәйрәм ителгән, гадәттә, төрле күңелле уеннар оештырылган. Өченче версиясе календарь алышыну белән бәйле. XVI гасырда Яңа ел 1 гыйнварда түгел, ә 1 апрельдә билгеләнгән. Яңа ел каникуллары 25 мартта башланып 1 апрельдә тәмамланган. Ул вакытта да елны озатканда шау-гөр килеп күңел ачканнар. Бәйрәмдә шаяру гадәтләрен кешеләр табигатьтән алган, диючеләр дә бар. Яз көне һава торышы төрлечә була, әле кояш чыга, аннары суытып та җибәрергә күп сорамый.

Агачлар әлегә шәрә,

Утыралар боегып.

Салкынча җилләр искәндә,

Ак шәлләрен ябынып.

Кар ята тирә якларда,

Тиздән язлары җитәр.

Кояш нурларын сибүгә,

Гөрләвекләр дә китәр.

Кошлар кайтыр җылы яктан,

Сагынып туган ягын.

Өй кыекларына кунып,

Сузып сайрарлар тагын.

## Апрель аенда нинди бәйрәмнәр көтелә?

1 апрель- «Көлке көне»
2 апрель - Халыкара балалар китабы көне
4 апрель - Халыкара Интернет көне
5 апрель - Дөньякүләм мультфильмнар көне
7 апрель - Бөтендөнья сәламәтлек көне
8 апрель - Хәрби коммисариат хезмәткәрләре көне
11 апрель - фашист концлагерьларыннан тоткыннарны азат итү көне
12 апрель - Авиация һәм космонавтика көне
13 апрель - Бөтендөнья рок-н-ролл көне
15 апрель- Халыкара мәдәният көне
18 апрель - Халыкара һәйкәлләр һәм тарихи истәлекле урыннар көне
20 апрель – Пасха
22 апрель - Халыкара Җир көне
23 апрель - Халыкара инглиз теле көне
26апрель - Бөек татар шагыйре Габдулла Тукай туган көн
28 апрель - Халыкара хезмәтне саклау көне
29 апрель - Халыкара бию көне

МНОГОПРОФИЛЬНАЯ
ШКОЛА №181

**Редакциянең адресы:**
420101, Казан шәһәре,
Тулпар урамы, 2
Тел. 89050229576

**Тираж** – 50 экз.

**Баш мөхәррир һәм дизайнер:**
Габдуллаҗанова А.Ф.
**Редколлегия әгъзалары:**
Мәхмүтова Мәдинә, Хәйриев Самат, Вәлиева Диләрә, Мельникова Аделина, Мәхмүтова Мәликә, Хөснетдинова Камелия